РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУЕМБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Туембаш

от «11» апреля 2022 года № 7

**Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылында «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Чуллы авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Туембаш авыл җирлеге Уставы нигезендә Туембаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2022 елның 25 апреленә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Чуллы авылы, Хаҗи Закиров урамы, 2 А йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 25 апреленә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Чуллы авылы, Хаҗи Закиров урамы, 2 А йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Чуллы авылы

гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- Нократ Аланы-Малмыж трассасыннан Чуллы авылына кадәр килү юлын вак таш-асфальт җәеп ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар белән тулыландырырга:

« - Чуллы авылы су башнясы өчен насос сатып алу;

«- Чуллы авыл клубын тоту (теннис өстәле сатып алу)»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

ОГРН 1021607753331
ИНН 1623003900

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И. Ф.Гарипов